**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.01.2017 Балык Бистәсе штп. № 05пи

2017 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет һәм башка кулланучылары өчен торак-коммуналь хезмәтләргә тарифлар турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы, Татарстан Республикасы Президентының «2017 елга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индекслары турында»2016 елның 28 ноябрендәге ПУ-1055 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкка күрсәтелә торган торак һәм коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын һәм алар өчен түләү күләменең нигезлелеген арттыру чаралары турында " 2010 елның 9 апрелендәге 250 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы уставының 46 статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты нигезендә карар бирәм:

1.2017 елның 1 гыйнварыннан түбәндәге тарифларны расларга һәм гамәлгә кертергә:

- 2017 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы буенча гамәлдәге су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу челтәрләренә тоташтыруга түләү күләме (№1 кушымта);

-2017 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы буенча бюджет һәм башка кулланучыларга каты көнкүреш калдыкларын һәм сыек көнкүреш калдыкларын җыю һәм чыгару өчен түләү күләме (2 нче кушымта).

2.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә һәм 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Д. А. Низамовка йөкләргә.

Җитәкче Р. Х. Хәбибуллин

Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының 2017 елның 12
гыйнварындагы № 05пи карарына
кушымта№1

**2017 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы буенча гамәлдәге су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу челтәрләренә тоташтыруга түләүнең күләме**

| Түләү атамасы | Хезмәт күрсәтү төре | Хезмәтне үлчәү берәмлеге өчен база ставкасы (сумнарда) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Гамәлдәге су белән тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру өчен тариф | тоташтыру | 4000,00 |
| Гамәлдәге су бүлү челтәрләренә тоташтыру өчен тариф | тоташтыру | 4000,00 |

Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының 2017
елның 12 гыйнварындагы № 05пи
карарына  кушымта№2

**2017 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы буенча бюджет һәм башка кулланучыларга каты көнкүреш калдыкларын һәм сыек көнкүреш калдыкларын җыю һәм чыгару өчен түләү күләме**

| Түләү атамасы | Хезмәтне үлчәү берәмлеге | Тарифлар (сумнарда) | |
|---|---|---|---|
| | | 01.01.2017 дән 30.06.2017 кадәр | 01.07.2017 дән 31.12.2017 кадәр |
| Сыек көнкүреш калдыкларын чыгару | м.куб. | 550,0 | 600,0 |
| Каты көнкүреш калдыкларын җыю һәм чыгару | м.куб. | 1124,0 | 1168,0 |